| | |
|---|---|
| ГЛАВА ШАРЛИАРЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 9 КАРАР

**29 декабрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 438-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» 2021 елның 6 маендагы 5 номерлы карары, «Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль законы, Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 декабрендәге 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә карар иттем:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - Шәрләрәмә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе;

- гавами тыңлаулар үткәрү вакыты - 2024 елның 12 гыйнварендә 14 сәгатьтә;

- үткәрелү урыны - Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының утырышлар залында (Шәрләрәмә ав., Мәктәп ур., 57).;

- фикер алыша торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты, Мәктәп ур., 57урамы адресы буенча (эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр) кертелергә мөмкин.

4. Шәрләрәмә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http//sarmanovo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөклим.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Хуҗина

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгының 2023елның 29 декабрендәге карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү**

1) 32 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Территориаль зоналар чикләре муниципаль берәмлекләр, торак пунктлар, җир кишәрлекләре чикләрен кисеп үтә алмый (Россия Федерациясе Җир кодексында яисә башка федераль законда каралган очракларда чикләре территориаль зоналар чикләрен кисеп үтә ала торган җир кишәрлегеннән тыш). Территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләреннән, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән файдалануның махсус шартлары булган территориаль зоналар чикләре белән кисешү рөхсәт ителә.";

2) 30 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацына түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«- Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына торак пунктлар чикләре турында белешмәләр кертелгәндә федераль закон нигезендә үзгәртелү нигезендә Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрындагы территориаль планлаштыру документларындагы торак пунктлар чикләренең урнашу урыны (шул исәптән торак пунктлар) белән җир кишәрлекләре чикләре кисешкән очракта) турындагы белешмәләрнең күрсәтелгән торак пунктлар чикләренең урнашу урыны турында тасвирламасына туры килмәве.»;

3) 27 статьяның 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункт өстәргә:

«5.1) әгәр мондый килештерү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40_1 статьясында каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше тышкы күренешен килештерү;».